Бөтендөнья балалары, дуслашыгыз!



Сабантуй

15 апрель, 1995 ел.
№ 28
(4642)

БАЛАЛАР ҺӘМ ЯШҮСМЕРЛӘР ГАЗЕТАСЫ

Без ул бәйрәм бизәге






БЕЗ — тормышның чәчәкләре. Өлкәннәр үзләре шулай диләр. Без — балалар, теләсә нинди бәйрәмнең дә бизәге була алабыз. Әле менә Казанда куйган концертларда районыбыз данын күтәрдек. Якташларыбыз җыелган залда иң күп алкышлар безнең адреска булгандыр. Мактану түгел, дөресе шул. Җырладык та, биедек тә, уйнадык та. Кыскасы, Мөслим ягының да, Минзәлә халкының да төшеп калганнардан түгеллеген расладык.

Минзәлә һәм Мөслим балалары сүзен ишетеп фотохәбәрче Мидхәт ШАКИРҖАНОВ төшергән фоторәсемнәр.











«Сабантуе»ма



«Сабантуе»м!
Синнән дәрт, моң алып
Яши нәни татар баласы.
Буйга җитеп инде зур булсам да,
Килә дустың булып каласым.

Шигъри дәртең миңа күчкән инде,
Учак булып яна йөрәктә.
Балачагым дусты булганлыктан
Яратамын сине бигрәк тә.

Тәүге иҗат җимешем дә минем
Синең белән уртак булганга,
Каләм алып сиңа хатлар язам
Күңелемдә хисләр тулганда.

Җитмеш яшең тулды «Сабантуе»м,
Минем бүләк — изге теләкләр.
Син яшәсән, газиз газетабыз,
Суынмаслар безнең йөрәкләр.

Эльмира ҖӘЛИЛОВА.
Актаныш, Аеш.



Беренче класста укытучы укучыдан:
— Син саный беләсеңме? — дип сорый.
— Беләм. Бер, ике, өч, дүрт...
— Ә аннан?
— Биш, алты, җиде, сигез...
— Дәвам ит.
— Тугыз, ун, валет, дама, король...

* * *

Дәү әнисе оныгыннан сорый:
— Рәшит улым, син миңа фәнни итеп аңлатып бир әле: ни өчен иң беренче яшен яшьнәгәнен күрәм, ә аннан соң гына күк күкрәгәнен ишетәм.
— Бик гади аңлатыла ул, дәү әнием. Синең бит күзләрең алдарак, ә колакларың арттарак урнашкан...

* * *

— Әни, суыткычтан тортны алып куй әле.
— Алдым, улым. Ничә өлешкә кисим: дүрткәме, әллә сигезгәме?
— Дүрткә генә бүл, әнием. Сигез кисәкне ашап бетерә алмам мин...

* * *

Математика укытучысы укучысының дәфтәрендәге чишелешләрне тикшереп шакката да болай ди:
— Бүген икебезнең беребез акылдан язган ахры, Галимов!
Икенче көнне Галимов укытучы өстәленә конверт китереп куя.
— Конверт эчендә нәрсә? — дип сорый укытучы.
— Минем акылдан язмаганлыгым турында мәктәп табибы биргән белешмә...

* * *

— Сез ничек уйлыйсыз, рәссам үзенең бу рәсемендә таң атканны күрсәткәнме, әллә кояш баеганнымы?
— Кояш баеганны.
— Ник алай уйлыйсыз?
— Мин бу рәссамны яхшы беләм. Ул төштән соң гына йокыдан тора.

Рабит Батулла



БАТУЛЛА ТУРЫНДА КАЛӘМДӘШЛӘРЕ:

«ИҢ ЭЛЕК шуны әйтергә кирәк: бу яшь автор шактый күзәтүчән, ул тирә-яктагы күренешләргә гади күз белән генә карамый, ә халык әйткәнчә, күңел күзе белән карый, кешеләрнең эчке дөньяларына керә белә, аларның характерларын ачып күрсәтергә тырыша. Болар язучылык юлына басучылар өчен бик кирәкле сыйфатлар. Шунысы өстенә Батулла иптәш сюжетны мавыктыргыч итеп корырга омтыла... Теле дә шома һәм йөгерек».

Гариф ГАЛИЕВ. 16. 12. 1964.
Нәшрият, эчке рецензия.

«БАТУЛЛАНЫҢ «Тылсымлы Әбугалисина» пьесасы курчак театрлары өчен язылган классик әсәрләр таләбенә тулысы белән җавап бирә».

Сергей ОБРАЗЦОВ.
Югары курслар, 1967.

«БАТУЛЛАНЫҢ кыска һәм характерлы табылган диалоглар аша хикәяләргә тырышуы һәм, шуның өстенә, тагын сатирик сәләте игътибарны үзенә җәлеп итә».

Фатих ХӨСНИ.
«Татарстан яшьләре», 12. 12. 67.

«БАТУЛЛА татар әдәбиятында бүген беркем диярлек шөгыльләнми торган жанрда иҗат итә. Ул балалар өчен әкиятләр яза. Баланың әдәбият белән, гомумән, китап белән танышуы әкияттән башланганлыгын һәм шигъри фантазияне үстерүдә, баланың характерын тәрбияләүдә әкиятнең әһәмияте чиксез зур икәнлеген искә төшерсәк, Батулланың бу изге эше турында мактаудан башка берни әйтеп булмый».

Нурихан ФӘТТАХ.
Нәшрият, эчке рецензия, 26. 02. 72.

«ТАЛАНТЛЫ әкиятче Батулланың диапозоны киң, мөмкинлеге зур, әдәбиятыбызда аңа көндәшләр юк, димәк, яз да яз гына!»

Аяз ГЫЙЛӘҖЕВ,
Нәшрият, эчке рецензия.
21. 06. 1977.

«ӘКИЯТ язган язучы беркайчан да онытылмаячак. Чөнки әкиятне балалар укый, алар үскәннән соң үз балаларына шул әкиятләрне сөйләячәк. Һәм шулай мәңгегә әкият яшәячәк. Колхоз, совхоз, КамАЗ, Әлмәт нефте турындагы әсәрләрнең күбесе инде күптән искерде, әкиятләр искермәячәк.

Язучы буласы килгән кеше «һичшиксез» татар халык әкиятләре аша килергә тиеш. Аннан соң башка халык әкиятләрен һәм әдипләр иҗат иткән әкиятләрне укып-өйрәнгән кеше, шөбһәсез, бай рухлы кеше булачак.

Мин Батуллаың «Алып батыр маҗаралары» һәм башка әкиятләрен кибернетика, фәлсәфә дәресләрендә студентларга мисал буларак кулланам.»

Җәүдәт СӨЛӘЙМАН, кибернетик,
шагыйрь. 1986.

«ХӨРМӘТЛЕ Батулла! Нижний Тагиль курчак таеатрында сезнең «Курай уйный бер малай» пьесагызның премьерасы 1980 елның 28 мартында булды. Әкиятне балалар гына түгел, олылар да бик яратып карый. Шәп драматургиягез өчен сезгә олуг рәхмәт!»

Нижний Тагиль курчак театрының
тәрбиячесе Н. Качанова язган хаттан.
25. 02. 81.

«БУ ӘСӘР («Алып батыр маҗаралары») Батулла иҗатында аерым, мөһим урын алып тора, аның зур уңышларыннан берсе дип уйлыйм... Бу әсәрне укыганда үзеңне ана телебезнең, халкыбызның тарихының бәйрәмендә йөргән кебек хис итәсең».

Рәниф ШӘРИФ.
«Казан утлары», 1987 ел, 2 сан.

«БАТУЛЛА, күрәсең, бу зур китабы белән («Юл буенда зәңгәр чәчәк») илле еллык юбилеена килә һәм шушы китап, ниһаять, әдәбиятта аның урынын беркетеп куя инде. Бу беркетелгән урыннан ул инде төшмәячәк, аннан күтәрелеп кенә барачак».

Мөхәммәд МӘҺДИ.
Нәшрият, эчке рецензия, 9. 07. 87.

«СИРАТ КҮПЕРЕ» — Батулланың театр сәнгате өлкәсендәге билгеле бер уңышы, исемен драматургиядә тагын да ныгыткан җитди хезмәте... Батулланың бөтен хикәяләре дә диярлек кинаяле, аларның һәрберсендә тел төбенә яшеренгән сер ята... Ул янып, бирелеп, фидакарьләрчә эшләргә яратылган кеше, кешеләрне үзе белән әйдәргә, кешеләрнең дә йөрәкләрен үзенеке кебек яндырырга алынган кеше. Тынгысызлык, бирелгәнлек, иманлылык хас аңа. Батулла безнең буынның бер бизәге, арабызда аның булуы үзе бер куаныч безгә».


Равил ФӘЙЗУЛЛИН.
«Социалистик Татарстан»
27. 03. [illegible]8.

«БАТУЛЛАНЫҢ иҗаты күпкырлы. Ләкин ул нәрсәгә генә тотынса да, һичшиксез, үзенең төп сыйфатын күрсәтә — ул олы мәгънәсендә әдип-рәссам».

Мәдинә МАЛИКОВА.
«Вечерняя Казань» 31. 03. 1988.

«ҮТКӘН елгы (1987) театр хәрәкәтендә вакыйга буларак саналырлык премьера булдымы?— дип сораганда, мин Батулланың «Сират күпере»н әйтер идем. Авторның һәм театрның иң зур уңышы — бөек Тукайның шундый ук тирән дәрәҗәдә символик Шәүлә образы аша күрсәтелгән царизмга каршы көрәшнең куелуында. Г. Тукай үз тормыш юлында очраган сират күперләрен бөек рухлы даһиларча уза. Аның һәр көне — батырлык. Батулла әнә шуны сәнгатьчә бирә алган».

Ризван ХӘМИД.



ОЧА ТОРГАН ТИЕН

Әкият

Мөбарәк яши торган авыл бик матур. Авыл янында гына карурман шаулый. Урманда тиеннәр, көртлекләр, төлкеләр очрый.

Менә Мөбарәк, мылтык асып, урман буйлап бара. Тирә-якта кошлар сайрый. Кайдадыр саескан чыкылдый. Тиеннәр сызгыра. Сукмак буйлап, чаштыр-поштыр яфраклар кыштырдатып керпе йөри. Сукмак янында бөгәрләнеп елан йоклап ята. Бөтен урманны яңгыратып тукран тукылдый.

Шул чак нарат башыннан тиен атылды.

Бу — оча торган тиен. Аның алгы тәпиләре астында канат сыман ярысы бар. Сикергән вакытта ярылар канат шикелле җәелеп китә. Оча торган тиен бик ерак араны шулай сикереп-очып уза ала. Нәкъ кош кебек.

ТОРМЫШ ЮЛЫ

РАБИТ БАТУЛЛА (Роберт Мөхлис улы Батуллин) 1938 елның 26 мартында Татарстанның Зәй районы Түбән Оложы авылында укытучы гаиләсендә туа. 1955 елда Биш Авылы урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, бер ел шул ук районның Кадер җидееллык мәктәбендә балалар укыта. 1956-1961 елларда Мәскәүдә М. С. Щепкин исемендәге театр училищесында укый, аны тәмамлагач, Казанга кайтып, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында эшли. 1963-1965 елларда Казан дәүләт курчак театрында һәм Казан телестудиясендә режиссер вазифаларын башкара. 1965-1966 елларда Мәскәү театр институты каршындагы Югары режиссерлык курсларын тәмамлап кайткач, 1977 елга кадәр башта Казан курчак театрында баш режиссер, аннары Казан дәүләт мәдәният институтында режиссер-педагог булып эшли. 1977-1979 елларда янә Мәскәүгә китеп М. Горький исемендәге әдәбият институты каршындагы Югары әдәби курсларда укый. Курсларны тәмамлап кайткач театр училищесында укытучы, К. Тинчурин исемендәге драма һәм комедия театрында баш режиссер булып эшли.

Р. Батулла төрле жанрда иҗат итә — әкиятләр, хикәяләр, мәзәкләр, повесть һәм романнар, пьесалар яза.

1985 елда Р. Батуллага Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исем бирелде. 1991 елда ул Татарстан Язучылар берлегенең Г. Исхакый исемендәгне бүләгенә лаек булды. «Ялкын» журналының А. Алиш исемендәге премиясе белән бүләкләнде.

БАСЫЛЫП ЧЫККАН КИТАПЛАРЫ

1. *Исемем минем Дүрткүз. 1966. Казан.*
2. *Каникуллар дәвам итә. 1967.*
3. *Могҗизалы тамаша. 1968.*
4. *Уйларымны кеше белсен. 1969.*
5. *Куян баласы Нуяк. 1970.*
6. *Алтын куллы Гөлчәһрә. 1974.*
7. *Пәһлеваннар иле. 1977.*
8. *Әкият сөйлим сезгә. 1979.*
9. *Курай уйный бер малай. 1987. Мәскәү.*
10. *Төш вакытындагы могҗиза. 1979, урысча, Мәскәү.*
11. *Ташламам, җаникисәгем. 1980.*
12. *Серле сандык. 1983.*
13. *Сын-журавль. 1983, урысча, Мәскәү.*
14. *Чебен гөмбәсе. 1985.*
15. *Алып батыр маҗаралары. 1986.*
16. *Кичер мине, әнкәй. 1988.*
17. *Бишек хикәятләре. 1989.*
18. *Юл буенда зәңгәр чәчәк. 1990.*
19. *Сөембикә. 1992.*



булдымы?— дип сораганда, мин Батулланың «Сират күпере»н әйтер идем. Авторның һәм театрның иң зур уңышы — бөек Тукайның шундый ук тирән дәрәҗәдә символик Шәүлә образы аша күрсәтелгән царизмга каршы көрәшнең куелуында. Г. Тукай үз тормыш юлында очраган сират күперләрен бөек рухлы даһиларча уза. Аның һәр көне — батырлык. Батулла әнә шуны сәнгатьчә бирә алган».

Ризван ХӘМИД.
«Социалистик Татарстан» 7. 05. 1988.

«ЗАМАНЫНДА Тинчурин, Фәйзи, Исәнбәт шикелле, Батулланың да иҗаты гаҗәеп күпкырлы: әкиятләр дә, хикәяләр дә яза ул, повестьлары да бар аның, әдәбиятыбыз-сәнгатебездәге олы шәхесләр турында китап язарга материал да җыя, театр училищесында яшьләрне актерлык осталыгына да өйрәтә, режиссер буларак, театрда спектакльләр дә куя. Актерлар йортында әдәбият-сәнгать кичәләре дә у[illegible]ра, өстәвенә, драмалар, миниатюралар иҗат итәргә дә өлгерә.

— Чәчелә Батулла...— диләр.

Чәчелми Батулла! Ул язмыш-тәкъдир тарафыннан мул бирелгән сәләтен кызганмыйча әдәбиятка-сәнгатькә, халыкка калдырырга тырыша».

Рөстәм МИНГАЛИМ.
Батулланың «Кичер мине, әнкәй!» китабына кереш сүз. 1988.

«ЮЛ БУЕНДА ЗӘҢГӘР ЧӘЧӘК» — безнең татар әдәбиятының зур уңышы. Безнең әдәбиятта шундый төгәл такт, югары культура һәм искиткеч көчле ихласлык белән язылган әсәрләр сирәк... Балалар, җәнлекләр дөньясын чынбарлыктагыдан да реаль әкиятләр яза алуына сокланып туймый идем моңа кадәр, бу әсәр Батулланы татар әдәбиятының иң беренче сафында баручы язучылар рәтенә бастырды».

Миргазыян ЮНЫС.
«Казан утлары», 1991, 9 сан.

«БУ ӘСӘРНЕ («Сөембикә»не) безнең замандаш, безнең белән сөйләшеп, аралашып яшәгән кеше түгел, ә шул дәвердә Мөхәммәдьярлар белән бергә яшәгән 16 нчы йөз язучысы язып калдыргандыр кебек кабул ителә. Моның сәбәбе бер генә. Әсәрдә язучының теле камил! Бер китапта бөтен тарихи вакыйгаларны бәйнә-бәйнә ачып бирү мөмкин түгел. Булган кадәресе, язылган һәм без укыган кадәресе, һичшиксез, соклану һәм олы ихтирамга лаек».

Мөхәммәт МИРЗА.
«Ватаным Татарстан», 24. 03. 1995.

«Батулланың Камал театрында бара торган «Кичер мине, әнкәй!» пьесасы шикелле бер әсәр язсам, мин кабат берни язмасам да үкенмәс идем».

Гариф АХУНОВ.
1980.

ЩЕПКИН исемендәге театр училищесы студентлары Ә. Фәйзи (беренче рәттә уртада) янында. Батулла икенче рәттә уңнан икенче. Мәскәү, 1956 ел.

Щепкинчылар 1992 елда.

Шул чак нарат башыннан тиен атылды.

Бу — оча торган тиен. Аның алгы тәпиләре астында канат сыман ярысы бар. Сикергән вакытта ярылар канат шикелле җәелеп китә. Оча торган тиен бик ерак араны шулай сикереп-очып уза ала. Нәкъ кош кебек.

Тиен нараттан имәнгә таба оча. Мөбарәк тиз генә мылтыгын иңеннән алды да тиенгә атты.

Урман селкенеп куйды!

Тукран тукылдавыннан туктады. Саескан тавышы тынды. Йоклап ятучы елан сискәнеп уянды да тиз генә үләннәр арасына кереп шылды. Агач башындагы каргалар, шомлы кычкырып, дәррәү күтәрелделәр. Төнен ауда йөреп арган мәчебашлы ябалак та куркып уянды. Ул-бу булмагае дип, бер агачтан икенчесенә күчеп утырды.

Тиен очып барган җиреннән, кинәт чайкалып, таш кебек аска томырылды. Ул агач ботакларына бәргәләнә-бәргәләнә Мөбарәк басып торган сукмак өстенә килеп төште. Төште дә тыпырчына башлады. Мөбарәк йөгереп килеп җитте. Тиеннең канаты яраланган иде. Мескен тиен, Мөбарәктән качарга тырышып, үлән арасына китәргә азаплана.

Шундый матур очып бара иде! Әйтерсең лә бөркет!

Тәпиләре неп-нечкә, үзе дер-дер калтырый. Тиен, үтерсәң үтер инде, дигәндәй, сыртына ятып бәләкәй аучыга карады. Мөбарәк бу караштан куркып китте. Тирә-якта берәү дә юк. Берәрсе качып кына карап тормадымы икән? Әгәр кеше күрсә, ни оят! Ни оят!

Мөбарәк тиенне кулына алды. Тиен чиелдый. Үзе, ни эшләтерсең икән дигәндәй, Мөбарәккә карый.

Мөбарәк яраланган тиенне чыршы ботагына куйды.

Бәлки терелер, ярасы төзәлер әле. Ядрә сөягенә тимәгән, канат ярысын гына ертып киткән. Җөйләнер әле, җөйләнер!

Шул көннән соң Мөбарәкләр урманында бер генә тиен дә калмаган. Барча тиеннәр дә бу урманны ташлап киткәннәр ди.

Сулдан уңга — Я. Халитов, Ә. Еники, А. Гыйләҗев, В. Нуруллин, Р. Батулла.

Бакчасарай, 1991 ел. Батулла Кырым татарлары милли хәрәкәте вәкилләре арасында. Өстәл артында милли хәрәкәт лидеры Мостафа Җәмил.

Уңнан сулга: М. Зарипов, бөек әкиятче Дж. Родари, Г. Ахунов, Р. Батулла. 1969 ел.

Җырчы Галия Кайбицкая (сулдан уңга), драматург Риза Ишморат, Баян Гыйззәт, К. Тинчурин хатыны Заһидә ханым, Батулла. 1987 ел.

Батулла гаиләсе белән — хатыны Рузия ханым, уллары Нурбәк һәм Байбулат. 1994 ел.

Батулла әнисе Мөкәррәмә апа белән. 1986 ел.

Мәҗит Рафиковның тууына — 70 ел.

Якты һәм җылы бөркелә

Бу әдипнең исемен әйтү белән минем күз алдына якты, кояшлы җәй көннәре — Аккош күлендәге иҗат йортында аның белән бергә янәшә яшәлгән бик тә матур көннәр килеп баса... Һәм ул шәхес үзе дә хәтердә әнә шундый кояшлы җәйге көн кебек булып сакланып калган.

Әйе, Мәҗит ага Рафиков — чын-чыннан зыялы зат, югары тәрбияле һәм бик тә укымышлы шәхес иде. Аның белән икәү генә калганда ул сине үзеңә дә сиздермичә генә тормыштагы, табигатьтәге, әдәбияттагы гүзәллекнең иң нечкә хасиятләре хакында гаҗәеп мәгънәле әңгәмәләргә алып кереп китә. Андый чакларда синең әңгәмәдәшең булган бу кешенең дөньяны һәм матурлыкны шундый да нечкә тою, шундый да тирәннән аңлау талантына сокланасың. Аның белән бергә үзең дә матурлыкның яңа үрләренә күңелеңнән генә өр-яңа сукмаклар саласың...

Менә ул татарның иң затлы шагыйрьләре язган әсәрләрне сөйли. Алардагы эстетик байлыкка, фикри тирәнлеккә ушы китеп, дөньясын онытып тора... Менә ул урысчага күчеп, Иван Бунин шигырьләрен яттан укый. Афанасий Фет әсәрләреннән күпләп-күпләп өзекләр китерә... Шулай ук чит илләр әдәбиятын да бик яхшы белә иде Мәҗит ага.

Аның үз әсәрләре дә дөнья әдәбиятының бөек әсәрләренә хас булган әнә шул кыйммәтле сыйфатларга ия иделәр. Аларда да кеше җанының, кеше рухының югары яшәеше гаҗәеп табигый булып һәм тәэсирле чагылды. Мәҗит Рафиковның күләм ягыннан әллә ни зур булмаган әсәрләре кеше күңеленең кадерле һәм изге мизгелләре хакында укучы белән ихлас әңгәмә алып баралар.

Мәҗит Рафиковның 1966 елда «Илһам авазы» дигән хикәяләр җыентыгы, 1973 елда «Төлке улы Хәйләпүш» дигән шигырь китабы, 1975 елда «Су башы» исемле повестьлар һәм хикәяләр җыентыгы дөнья күрде.

Бу әдип бердәй осталык белән урыс телендә дә иҗат итте. Аның урысча басылган «Родник Хабира-Соловья» (1972), «Ишкильды» (1975) һәм «Школа на взгорке» (1981) китаплары бар.

Әдипнең «Шарлама», «Сиңа ничә яшь?» һ. б. әсәрләре чит илләрдә дә басылып чыкты, «Безнең авыл мәктәбе» повесте исә 1977 елда «Волга» журналында дөнья күреп, иң яхшы әсәрләргә бирелә торган бүләккә лаек булды.

Ул бик тә шигъри җанлы әдип иде. Проза әсәрләре язып бетереп «хәл җыйган» арада үзе дә байтак кына һәм әйбәт шигырьләр язды. Алар 1985 елда «Гүзәл мизгелләр» дигән исем белән Татарстан китап нәшриятында басылып та чыктылар, матбугатта яхшы бәя алдылар.

Сүзгә гаять сизгерлеге Мәҗит Рафиковның тәрҗемә эшчәнлегендә дә күренде. Аның тәрҗемәсендә Г. Тукайның прозасы, Ш. Камал, Н. Дәүли, М. Әмир, И. Гази, Г. Әпсәләмов, Ә. Еники, Р. Төхфәтуллин, Х. Сарьян һ. б. язучыларның күп кенә хикәяләре урысча дөнья күрде. Гомеренең соңгы елларында ул бик тә бирелеп һәм ихлас күңелдән мавыгып Тукайның чәчмә әсәрләрен урыс теленә тәрҗемә итте. Ул бөек шагыйребез язган һәр сүзнең тулы мәгънәсе, бөтен тирәнлеге, саллылыгы урыс укучысына һәм бу тел аша дөнья халкына аңлашылсын дип тырышты. Бу эшкә үзенең поэтик һәм фәлсәфи көчен салды, кызганмады. Мәҗит Рафиковның вафатыннан соң дөнья күргән китап, минемчә, көченең юкка сарыф ителмәгәнлеген раслый.

Әйе, Мәҗит Рафиков дөньяны, тормышны киң колачлап һәм киң күңел белән яшәүче әдип иде. Әнә шуңа күрә аның әсәрләрендә безгә Олы Хакыйкать юлдаш булып бара, Бөек Матурлык күңелләрне җылытып тора. Аның иҗаты турында язган тәнкыйтьчеләр дә бер дә юкка гына менә мондый сүзләр кулланмаганнардыр: «Фәлсәфи калыптагы әдип» (И. Ахунҗанов), «Матурлык эзләүче» (Ф. Миңнуллин) һ. б.

Мәҗит Рафиков — Бөек Ватан сугышында катнашкан һәм авыр яраланган кеше иде. Әнә шул яра соңгы елларда бигрәк тә үзен сиздерде, аның хәрәкәтләнүенә нык комачаулады.

Әдип Сталин системасының җәзаларын бик иртә татый — аны студент чагында ук кулга алалар һәм Себергә сөргенгә сөрәләр. М. Рафиков 1950-55 елларда Иркутск өлкәсендә, Тайшет-Братск тимер юлы төзелешендә эшли.

Совет концлагерьларын кичергән кеше булса да, аннан үзенең кешелеклелеген, нечкә күңеллеген җуймый кайткан, саф йөрәкле зат иде ул. Матурлык һәм гаделлек ахырга кадәр аның төп таянычы булды.

... Җәйнең ямьле, матур, кояшлы көннәре «Аккош күле»ндә хәзер дә була... Һәм гаять моңсулатып, җаннарны серле билгесезлеккә төреп, андый ямьле көннәрнең эңгере дә килеп җитә... Әнә шундый кичләрдә, Мәҗит ага белән икәү яшәгән өйнең кояш баешына караган верандасына чыгып утырам да — дөньяның, дөньялыкның, тормышның Олы Хакыйкатен, Олы Матурлыгын тоеп һәм күреп яшәгән, әнә шуларга йөз тотып яшәгән олы җаннарны чын-чыннан сагына башлыйм... Һәм кичке эңгердә утырып үз эчемнән, үз күңелемнән генә алар белән башланган әңгәмәләрне дәвам итәм...

Мансур ВӘЛИ.

Яшь иҗатчылар мәктәбе

ИКЕНЧЕ ДӘРЕС

ИСӘНМЕСЕЗ, шигырь язучы нәни дусларым!

Яшь иҗатчылар мәктәбенең беренче дәресендә бәян ителгәннәр белән һәммәгез дә танышып чыккансыздыр дип уйлыйм. Әгәр аны укымыйча калучылар булса, һичшиксез, «Сабантуй» гәзитенең 13 март санын эзләп табып, беренче дәрес белән танышып чыгуларын сорыйм.

Бүгенге дәрестә без шигырь язганда бик кирәкле, шигырь төзелешендә мөһим саналган төп кануннарның берсе булган РИФМА төшенчәсен өйрәнербез.

Кайсы гына шигырьне алып укый башласагыз да, аларда һәр строфада, ягъни дүртьюллыкта, икенче һәм дүртенче юлларның соңгы сүзләре яңгырашлары белән бер-берсенә бик охшаш булуын күрерсез. Менә, мәсәлән, Г. Тукайның «Җир йокысы» шигыреннән бер өзек китерик:

Кырга ак кардан
Юрган *ябылган,*
Җир язга чаклы
Йокыга *талган.*

Җир йоклый тыныч,
Күреп тәмле *төш,*
Уяныр әле,
Тукта, үтсен *кыш.*

Түбәндәге сүзләргә игътибар итегез: *ябылган-талган, төш-кыш.* Яңгырашлары белән бер-берсенә охшаганнармы? Охшаганнар. Шигырьдәге юл ахырында килгән аваздаш кабатлаулар яки охшаш яңгырашлы сүзләр рифма дип атала. Рифма грекча аһәңлелек, ярашучанлык дигән мәгънәне белдерә. Рифма, гадәттә, шигырь юлларын чикләп килә һәм рифмаланучы ике сүзнең ярашуы бер строфа хасил итә. Рифмалар яңгырашларына, төзелешләренә шигырь юлының кайсы урынында килүенә карап, күп төрләргә бүленәләр. Ләкин без әлегә алар турыда сөйләшмибез. Бары тик рифманың иң гади һәм киң таралган очрагы — строфаның икенче һәм дүртенче юлларын тәмамлап килүче рифмалар турында гына сүз алып барачакбыз.

Шулай итеп, рифма — яңгырашы белән охшаш сүзләр. Әйдәгез, шундый сүзләр табып карыйк. Буш вакытларыгызда рифма тезеп уйнау да шигырь язган балалар өчен бик файдалы булачак.

Башладык:

Җиләк-чиләк, көрәк-йөрәк, акча-бакча, урам-буран, болан-елан, түгел-күңел, күлмәк-чүлмәк, таң котеп-аңкытып, бөркелә-гөр килә, тәмле-ямьле, чиста-оста, болын-колын...

Һәм шулай итеп бик күп дәвам итәргә мөмкин булыр иде. Чөнки телдә һәр сүзгә дә охшаш икенче, өченче сүзне табарга була. Бары тик бераз уйларга, башны эшләтеп алырга гына кирәк. Ә инде шигырь язганда бер-берсенә җиңелрәк яраша торган охшаш сүзләрне куллану отышлырак булыр. Гадәттә башлап шигырь язучылар (ә алар «Сабантуй»га үз шигырьләрен җибәрүче укучыларыбыз арасында бик күп) рифма ясауга бик игътибар итмиләр. Рифманың шигырьне матурлап торучы, аны шигырь итеп тотучы нәрсә икәнен онытып җибәрәләр яки бөтенләй белеп бетермиләр шикелле. Күп укучыларыбызның шигырьләрендә рифма бик нык аксый, ягъни ярашмаган сүзләрдән тора. Мисал өчен укучыларыбызның шигырьләренә тукталып үтик.

Яңа Чишмә районының Чаллы Башы урта мәктәбе татар теле һәм әдәбияты укытучысы Ландыш Хисмәтуллина үз укучыларының шигырьләрен безнең редакциягә җибәргән. Менә Гөлнар Дәүләтшинаның «Аккошлы күл» исемле шигыре.

Авылыбыз янында бар иде
Мин гашыйк зәңгәр аккошлы
күл.
Аккошлары күптән киткәннәр,
Бу күлне сагышлы иткәннәр.

Аккошсыз бу күлем нигәдер
Һәр көнне зар елый, моңая.
Минем дә сагышлы күңелем
Аккошсыз, аккошсыз
сызлана.

Ә, бәлки, бер көнне бу күлнең
Аккошлары кире кайтырлар,
Һәм алар мине һәр көн
Сагыштан юатырлар?!

Күргәнегезчә, бу өч строфалы шигырь. Беренче строфада Гөлназ, гадәттәге, икенче һәм дүртенче юлларның соңгы сүзләрен рифмалаштырмыйча, өченче һәм дүртенче юлларны рифмалаштырган. Ләкин гадәти принцип бозылганлыктан, строфа шигырь юлы кебек укылмый. Бу очракта беренче һәм икенче юллар да рифмалашырга тиеш иде. Ә икенче строфада Гөлназ *моңая-сызлана,* өченчедә *кайтырлар-юатырлар* сүзләрен рифма дип тапкан. Күреп торасыз: икесе дә уңышсыз. Әйдәгез, хәзер үзебез шушы сүзләрдән рифма ясап карыйк.

Моңая — моң кая...

Сызлана — тозлана, бозлана, сабырсызлана...
Кайтырлар — әйтерләр, баетырлар...
Юатырлар — юратырлар, югалтырлар...

Башка укучыларның шигырьләрендә дә, кызганычка каршы, уңышлы рифма очрамады. Мәсәлән, алардагы *каргалар белән-дуслар белән, уяна-уйната, кузгалаэш кайный анда, баета-баета, кар казы-чыршысы, килгәннәр-дигәннәр, көлешеп-биешеп, куяннар-булалар, елгадан-кардан, килүенә-эретүенә, агачлар-җәйлар, тагын да - һаман да, урманда-болында* кебек сүзләрне һич кенә дә рифма дип атап булмый шул. Рифмалары аксау аркасында кайбер кызыклы гына кебек тоелган язмалар да шигырь булып җитешмәгән дигән нәтиҗә ясарга туры килә һәм, әлбәттә инде, без аларны «Сабантуй» битләрендә бастырып чыгара алмыйбыз. Менә, мәсәлән, Түбән Кама районы Кече Ерыклы мәктәбе укучысы Василий Захаровның «Айлы төн» шигыре.

Ялгыз ай балкый биектә,
Йолдызлы зәңгәр күктә.
Йөгереп төшеп көмеш нуры
Барлык җиһанны үбә.

Шул көмеш нурга коенып
Йоклый урман, басулар.
Матур төшләргә бирелгән
Болын, кырлар, бакчалар.

Ай йөзә кара тынлыкка
Якты нурларын сибеп.
Юлда калып адашканга
Кайту юлын күрсәтеп.

Шигырьне укып чыккач матур гына күренеш күз алдына килеп баса. Ләкин рифмаларның зәгыйфьлеге шигырьнең ямен боза. Ә инде уңышлы рифмалар табылганда Василий Захаровның бу язмасыннан матур гына шигырь килеп чыгар иде.

Шигырь төзелешенең мөһим өлеше булган рифма турында сөйләшүгә багышланган икенче дәресебезне өйгә эш белән бетерергә булдык. Ә өйгә эш итеп шигырь язучы нәни дусларыбызга шундый мәсьәлә бирмәкче булам. Сөекле шагыйребез Габдулла Тукайның бик мәгълүм бер шигырендә *яртысы* дигән сүзгә охшаш сүзләр рифмалашып килә. Кадерле дусларым, сез бу шигырьне эзләп маташмагыз, ә бәлки, үзегез шушы *яртысы* сүзенә охшаган яңгырашлы сүзләр уйлап табыгыз. Ә алдагы дәрестә без шушы өйгә эшне тикшерербез һәм рифманың башка кайбер төрләре турында сөйләшербез. Сезгә бүгенге дәрестә сөйләгәннәрне (язылганнарны) ныклап, игътибар белән өйрәнергә, рифмалашкан сүзләр эзләп уеннар үткәрергә, шигырьләр язып карарга киңәш бирәм.

Хәзергә хушыгыз, уңышлар теләп,

Рафис абыегыз КОРБАН.

Кызыклы шәкерт

Уртача ♪ - 76

Әй-дә-ле, Ак-бай! Өй-рән син
арт а-я-гың бер-лә тор;
Ау-ма, ау-ма! Туп-ту-ры тор,
төз у-тур, ях-шы у-тыр!

Г. ТУКАЙ шигыре — Илдус ХӘЙРИ көе

Әйдәле, Акбай! Өйрән син, арт аягың белән тор;
Аума, аума! Туп-туры тор, төз утыр, яхшы утыр!

— Ник газаплыйсың болай син, мин әле бик кечкенә;
Мин туганга тик ике айлап булыр, йә өч кенә.

Юк, кирәкми, мин өйрәнмим, минем уйныйсым килә;
Шул болыннарда ятасым, шунда ауныйсым килә.

Ах, җүләр маэмай! Тырыш яшьләй, зурайгач җайсыз ул;
Картаеп каткач буыннар — эш белү уңайсыз ул!

Баш мөхәррир
Роберт МИҢНУЛЛИН

Редколлегия: Шәүкәт ГАЛИЕВ, Илдар ЮЗЕЕВ, Галимҗан ГЫЙЛЬМАНОВ, Ләлә ГЫЙМАДИЕВА (җаваплы секретарь), Госман САДӘ (баш мөхәррир урынбасары).

«Сабантуй»ны оештыручылар — Татарстанның Халык Мәгарифе министрлыгы, Яшьләр оешмалары советы, Балалар фонды һәм редакциянең хезмәт коллективы. 1924 — 90 елларда «Яшь ленинчы» исеме белән чыкты.

Индекс — 54124. Тираж 13793

Адрес: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.

Телефоннар:
49-36-86, 49-36-90,
49-36-77, 49-36-88,
49-36-94, 53-57-37.

Ярдәм итәргә теләсәгез: р/счет 700161998/2345716 в Волжско-Камском акционерном банке РКЦ ГЦБ г. Казани МФО 265005 «Для фонда редакции».

Заказ 1814 Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты типографиясендә басылды. Басарга кул куелды: 1995 ел, 13 апрель, 15 сәгать.